ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ИВАНОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИВАНОВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12.09.2025 с. Ивановка № 8

Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү хакында.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы белән, карар бирәм:

1.Кадастр номеры 16:25:200201:107, мәйданы 2647 кв. м, Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Ивановка авыл җирлеге, Ивановка авылы, Родничная ур., 22 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында рөхсәт ителгән файдалану төре белән - «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» билгеләнгән җир кишәрлеген капиталь төзү объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:

- җир кишәрлеге чикләреннән 2 нче ноктадан 3 нче 0 м ноктага кадәр минималь чигенешләрне киметү өлешендә

2025 елның 30 сентябренә 17 сәгать 30 минутта.

3.Җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4.Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 04 октябреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://parvo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева